САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 24 17.12.2015
№ _________от ______________

«Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында нигезләмәне раслау хакында» Саба муниципаль районы Советының 2014 елның 14 декабрендәге 270 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәве турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясы, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 2 февралендәге УП-71 номерлы Указы, «Муниципаль хезмәт Вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районындагы муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 270 номерлы карарына 2015 елның 11 ноябрендәге 02-08-02-197-15 номерлы Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасының протестына карата атарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан бирелүче белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының 2014 елның 14 ноябрендәге 270 номерлы карарын һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында муниципаль

хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәвен үз көчләрен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
Башлыгы Р.Н. Минниханов